БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru. www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 223

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанс тәэмин итү чыганагы субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанс тәэмин итү чыганагы субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
223 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанс тәэмин итү чыганагы субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

## 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге карар Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан (алга таба - муниципаль район бюджеты) финанс тәэмин итү чыганагы субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнештәге Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

## 2 БҮЛЕК. МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БЮДЖЕТЫННАН БИРЕЛӘ ТОРГАН БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАР

1. Муниципаль район бюджетыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге формада бирелә:

1) Балтач муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджеты составында төзелә торган авыл җирлекләренә район финанс ярдәме фондыннан дотацияләр;

2) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше субсидияләр булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар;

3) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133 статьясында билгеләнгән очраклардагы субвенцияләр;

4) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.2 статьясында билгеләнгән очраклардагы субсидияләр;

5) башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен, шул исәптән төбәк һәм муниципаль программалар буенча аерым чараларны үтәүгә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар;

6) төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен шәһәр һәм авыл җирлекләре дәрәҗәсенә тапшырганда,  аларны хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар.

## 3 БҮЛЕК. МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БЮДЖЕТЫННАН БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАР БИРҮНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

1)Дотация бирү максаты:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясы нигезендә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр (алга таба-дотацияләр), җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Балтач муниципаль районы бюджетында Балтач муниципаль районы шәһәр җирлегенең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү максатларында карала.

Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләргә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләре нигезендә кабул ителә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында Балтач муниципаль районы Советы карары нигезендә бирелә.

Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләр шәһәр һәм авыл җирлекләренә район финанс ярдәме фондын барлыкка

китерә.

Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотация күләме Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.9 статьясында каралганча исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә (1 нче кушымта)

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Балтач муниципаль районы бюджетыннан дотацияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм аларның җирлекләр арасында бүленеше тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләре нигезендә билгеләнә.

Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме һәм аларның бүленеше чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы Балтач муниципаль районы Советы карары белән раслана. Әгәр Балтач муниципаль районы бюджеты проекты чираттагы финанс елына һәм план чорына расланса, план чорына шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүленмәгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен, муниципаль район бюджетыннан план чорының беренче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменең 20 проценттан артмаганын һәм план чорының икенче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменең 20 проценттан артмаганын раслау рөхсәт ителә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр хисаплы бюджет тәэмин ителеше әлеге муниципаль районның шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериесе буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артмаган шәһәр һәм авыл җирлекләренә бирелә. Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше салым базасыннан (салым потенциалыннан) чыгып шәһәр һәм авыл җирлеге бюджеты тарафыннан алынырга мөмкин булган бер кешегә салым керемнәре нисбәте һәм, халык структурасында, социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторларда аермаларны һәм бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясенә йогынты ясый торган шартларны исәпкә алып, Балтач муниципаль районы җирлекләре буенча уртача шундый ук күрсәткеч белән билгеләнә. Бюджет тәэмин ителешенең исәп-хисап дәрәҗәсе шәһәр һәм авыл җирлекләре буенча шәһәр һәм авыл җирлекләренең салым керемнәре чагыштырмасын тәэмин итә торган бердәм методика буенча, бюджет хезмәтләре исемлеге һәм бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны характерлый торган күрсәткечләр исемлеге буенча билгеләнә һәм шәһәр, авыл җирлекләре өчен аерым билгеләнергә мөмкин.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә, хисап чорында факттагы керемнәр һәм чыгымнар күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым җирлекләрнең фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.1 статьясындагы 4 пунктында каралган дотацияләр бирелгән очракта, Балтач муниципаль районының финанс органы Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыклары белән җирлекнең социаль-икътисадый үсеше һәм муниципаль финансларын савыктыру чаралары каралган килешүләр төзергә хокуклы.

Әлеге пунктта күрсәтелгән килешүләр төзү тәртибе, вакытлары һәм килешүләргә таләпләр Балтач муниципаль районы башкарма комитетының норматив документы белән билгеләнә.

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган субсидияләр торган башка бюджетара трансфертлар күрсәтелергә мөмкин.

Башка бюджетара трансфертлар чыгым йөкләмәләрен үтәү максатларында бирелә. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып тора. Башка бюджетара трансфертлар Балтач муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына һәм чыгым йөкләмәләре нигезендә каралган максатларга Балтач район башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Башка бюджетара трансфертлар билгеләнгән критерийларга җавап бирә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;

б) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәү;

Башка бюджетара трансфертлар алу өчен җирлек башкарма комитеты Балтач район башкарма комитеты билгеләгән вакытларда, ул расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә Балтач район башкарма комитетына гариза тапшыра.

Җирлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән формула буенча билгеләнә.

Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Балтач район башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

Башка бюджетара трансфертлар бирү Балтач район башкарма комитеты тарафыннан расланган формаларда Балтач район башкарма комитеты һәм җирлек башкарма комитеты арасында төзелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә карала:

- башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;
- башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;
- башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;
- башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру вакытлары һәм формалары;
- алучының башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешмәү нәтиҗәләре;
- бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;
- килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар нигезендә беркетелгән керем чыганакларының һәм бюджетара трансфертларның муниципаль район бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәк булган чыгымнар күләменә карата нисбәте 100 проценттан да ким булмаган җирлекләр саны;
- түләү вакытлары башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан читтә булган алынган муниципаль займнарның (муниципальные заимствования) башка бюджетара трансфертларны бирүне бюджет үтәлеше барышында гамәлгә ашырмаган җирлекләр саны.

Балтач район башкарма комитеты вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган хисаплылыкның үткәрелгән анализы нигезендә нәтиҗәлелек күрсәткечләре күрсәткечләренә ирешүне бәяләү гамәлгә ашырыла.

Авыл җирлеге башкарма комитеты Балтач район башкарма комитетына килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

Балтач район башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлек башкарма комитетына йөкләнә.

Башка бюджетара трансфертлар Балтач район башкарма комитеты тарафыннан җирлекләр бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының килешүдә билгеләнә торган вакытларда җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган счетларына күчерелә.

Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Балтач муниципаль районы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм башка максатларда кулланыла алмый.

Балтач район башкарма комитеты һәм Балтач муниципаль районының финанс бюджет палатасы башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тота.

3) Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 133 статьясы нигезендә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирелергә мөмкин.

Максат: Россия Федерациясенең яисә Россия Федерациясе субъектының тапшырылган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү

Җирлекләр бюджетлары арасында субвенцияләрне бүлү Балтач муниципаль район Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карары белән раслана.

Җирлекләр бюджетларына аерым чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бирелә торган субвенцияләр җирлек бюджетына күчерелә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып тора.

Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр тиешле йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру нормативларын исәпкә алып, бердәм методика буенча җирлекләр арасында бүленә.

4) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

Максат: Балтач муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турындагы карары белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу.

Субсидияләрнең максатчан билгеләнеше, субсидияләр бирү кагыйдәләре белән һәм Балтач муниципаль районы җирлекләренең финанслашулары өчен субсидияләр каралган чыгым йөкләмәләреннән чыгып, килешүләр белән билгеләнә.

5) башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган акчалар, шул исәптән шәһәр һәм авыл җирлекләре дәрәҗәсендә чыгымнарның аерым төрләрен гамәлгә ашыру өчен региональ һәм муниципаль программалар буенча аерым чараларны үтәүгә акчалар, район бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан тапшырылган акчалар күләмендә күчерелә.

Шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль район бюджетыннан тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның күләме, шәһәр һәм авыл җирлекләре арасында бүлү билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән методика нигезендә башкарыла.

6) Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасының тиешле законнары нигезендә кабул ителә торган Балтач муниципаль район Советының муниципаль хокукый актларында каралган очракларда һәм тәртиптә Шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирелергә мөмкин.

Шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль район бюджетыннан тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның күләме, шәһәр һәм авыл җирлекләре арасында бүленеше билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән методика нигезендә башкарыла.

Муниципаль район бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертларның күләме Балтач муниципаль район Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турындагы карары, шулай ук чираттагы финанс елына муниципаль район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Балтач муниципаль районы Советының карары белән билгеләнә.

## 4 БҮЛЕК. БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАРНЫ БИРҮ ШАРТЛАРЫ

Муниципаль район бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнарын, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәү шарты белән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга башка бюджетара

трансфертлардан тыш, төзелгән килешүләр нигезендә бирелә.

Шәһәр һәм авыл җирлекләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнарын, муниципаль берәмлекләр өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясында билгеләнгән чикләүләрне, бюджетара трансфертлар бирү максатларын үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 92.1 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән иң чик күрсәткечләрне бозганда, бюджетара трансфертлар бирү Балтач муниципаль районының финанс бюджет палатасы тарафыннан туктатылып тора.

Муниципаль район бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар муниципаль район бюджетының үз керемнәре һәм муниципаль район бюджетының финанс мөмкинлекләре һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар исәбеннән, шул исәптән бюджет тәэмин ителешен тигезләү максатларында шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр бирү исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы финанс елында күрсәтелгән максатларга тотылмаган максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертларның калган өлешләре шул максатларга чираттагы финанс елында файдаланылырга тиеш яисә Балтач муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына Балтач муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә муниципаль район бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләргә финанс ярдәме күрсәтүнең район фондыннан дотацияләр бүлү методикасы

1. Җирлекләргә финанс ярдәме район фонды (алга таба - ҖФЯРФ) акчалары җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм муниципаль районның барлык җирлекләре буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә муниципаль район составына керүче җирлекләр арасында бүленә.

2. Җирлекнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе аның салым потенциалының муниципаль район составына керүче барлык җирлекләр буенча, бер кешегә исәпләгәндә, бюджет хезмәтләре күрсәтү бәясенә йогынты ясый торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып исәпләнгән шундый ук күрсәткеченә нисбәте буларак исәпләнә. j-нчы җирлекнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^{j}_{расч} = \frac{УНП^{j} \times \sum_{j=1}^{n} Ч_{j}}{ИБР^{j} \times Ч^{j} \times \sum_{j=1}^{n} УНП_{j}},$$

биредә:

$БО^{j}_{расч}$ - j-нчы җирлекнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^{j}$ - j-нчы җирлекнең салым потенциалы;

$ИБР^{j}$ - j-нчы җирлекнең әлеге кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{j}$ - j-нчы җирлекнең халык саны;

n - муниципаль район җирлекләре саны.

3. Муниципаль районның j-нчы җирлекнең шартлы салым потенциалы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$УНП^{j} = k^{j} \times УНП,$$

биредә:

$УНП^{j}$ - j-нчы җирлекнең шартлы салым потенциалы;

УНП - муниципаль районның әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$k^{j}$ - районның салым потенциалында j-нчы җирлекнең шартлы салым потенциалы өлешен исәпкә ала торган коэффициент.

4. ҖФЯРФ акчалары катнаш ысул белән бүленә. Фонд акчаларының беренче өлеше бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын файдаланып; икенче өлеше - “гарантияләнгән минимумга” кадәр тигезләү ысулын файдаланып бүленә.

$$D^{j} = D^{j} + D^{j},$$

1 2

биредә:

$D^{j}$ - j-нчы җирлеккә ҖФЯРФ дотацияләренең гомуми күләме;

$D^{j}_{1}$ - j-нчы җирлеккә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләрнең бер өлеше күләме;

$D^{j}_{2}$ - j-нчы җирлеккә “гарантияләнгән минимумга” кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләрнең бер өлеше күләме;

5. Теге яисә бу ысул белән бүленә торган ҖФЯРФ өлешләре арасындагы нисбәт ел саен муниципаль район бюджеты проектын чираттагы финанс елына төзегәндә билгеләнә.

6. Бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын файдаланып, ҖФЯРФ акчаларының бер өлешен бүлү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$D^{j}_{1} = d_{\text{ПП}} \times V_{\text{ФФПМР}} \times \frac{H^{j}}{H},$$

биредә:

$D^{j}_{1}$ - j-нчы җирлеккә “гарантияләнгән минимумга” кадәр тигезләү ысулын файдаланып бүленә торган дотацияләрнең бер өлеше күләме;

$d_{\text{ПП}}$ - пропорциональ тигезләү методын кулланып бүленә торган ҖФЯРФ өлеше;

$V_{\text{ФФПМР}}$ - муниципаль районның ҖФЯРФ күләме;

$H^{j}$ - j-нчы җирлеккә бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

H - барлык җирлекләргә бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

7. j-нчы җирлеккә бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләмен түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$H^{j} = \text{ИБР}^{j} \times \text{Ч}^{j} \times (\text{К}^{j} - \text{БО}_{\text{расч}}) \times \frac{\sum_{j=1}^{n} \text{УНП}_{j}}{\sum_{j=1}^{n} \text{Ч}_{j}},$$

биредә:

$H^{j}$ - j-нчы җирлеккә бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле чаралар күләме;

$\text{ИБР}^{j}$ - әлеге кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган j-

нчы җирлекнең бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^j$ - j-нчы муниципаль берәмлекнең халык саны;

К - бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериесы;

$БО^j_{расч}$ - j-нчы җирлекнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП_j$ - j-нчы җирлекнең шартлы салым потенциалы;

n - ҖФЯРФ дотация алучы җирлекләр саны.

8. Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә җирлекләрнең суммар ихтыяҗлары һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендәге аерманы исәпкә алып билгеләнә.

9. Җирлекләргә бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә ирешү өчен җитми торган акчалар күләме бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннән кимрәк булган җирлекләр буенча гына исәпләнә (БОj < К).

10. ҖФЯРФ акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешенең ирешелгән дәрәҗәсе билгеләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган ҖФЯРФ акчаларының икенче өлешен бүлгәндә кулланыла:

$$БО^j_1 = БО^j + \frac{Н^j \times \sum_{j=1}^{n} Ч_j}{ИБР^j \times Ч^j \times \sum^{n} УНП},$$